ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте авылында

2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 25 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүти авылында гражданнар җыены нигезендә

Карар:

1. 2025 елда авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче балигъ булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертергә. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте (көндезге бүлектә укучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен роторлы чапкыч сатып алу);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Чүте авылының кышкы вакытында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту).

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Баулы

муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга ( http://bavly.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan.ru).

Гражданнар җыенында рәислек итүче___________ И. Н. Хәйруллин